Муниципальное автономное учреждение дополнительного образования города Набережные Челны "Детская школа искусств №13 (татарская)"

# *Декоратив-гамәли сәнгать дәресләрендә татар халык кәсепләрен өйрәнү*

***Зөлфия Дадашова,*** *13нче татар балалар сәнгать мәктәбе югары категорияле сынлы сәнгать укытучысы*

***Миңнур Зольникова,*** *13нче татар балалар сәнгать мәктәбе югары категорияле сынлы сәнгать укытучысы*



**г. Набережные Челны, 2020**

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән мәкаль коры урында тумаган. XX гасыр башларына Идел буе татарларының 150дән артык кәсебе билгеле, ди галимнәр. Агач эшкәртү, күн белән эшләү, туку-эрләү, тегү-чигү, киез басу... Һәр һөнәрнең үзенең аерым осталары булган. Һәм алар үзләренең эшләнмәләрен сәнгать дәрәҗәсенә җиткергәннәр. Әлеге традицияләр күп вакытлар буыннан-буынга күчеп килсә дә, илдә-көндә барган үзгәрешләр, техник алгарыш нәтиҗәсендә аларның күпчелегенә ихтыяҗ калмаган. Бүген исә халык һөнәрчелеге бездә нәкъ менә сәнгати яктан кызыксыну тудыра.

Без инде 15 елдан артык Яр Чаллы шәһәренең 13нче татар балалар сәнгать мәктәбендә эшлибез. Безнең мәктәптә укучылар рәсем сәнгатен алты төрле юнәлештә өйрәнә. Шуларның берсе — декоратив-гамәли сәнгать дәресләре. Әлеге дәресләрне алып барганда терминология мәсьәләсендә шактый кыенлыкларга юлыктык. Баксаң, бу өлкәдә без атамаларны, уйлап та тормыйча, рус телендә кулланабыз икән. Һөнәре булгач, аның атамасы да татарча булган бит инде, ул атамаларны, һичшиксез, телебезгә кайтарырга кирәк. Без шул юнәлештә беренче адымыбызны атладык, дип әйтә алабыз. Каюлы күн темасын өйрәнгәндә, бу өлкәгә кагылышлы атамалардан кечкенә бер сүзлек төзеп карарга булдык. Сүзлекне төзергә укучыларыбызны да җәлеп иттек. Бу эштә бигрәк тә безнең сәнгать мәктәбендә җиденче ел белем алучы Адилә Зарипова һәм Гөлнара Шәеховалар зур тырышлык күрсәтте. Китапханәләрдән, ачык чыганаклардан (интернеттан) бергәләп күп мәгълүмат тупладык. Татар теле укытучылары да бик ярдәм итте. Шулай итеп, уртак тырышлык белән, «Бизәкле татар декоратив-гамәли сәнгать атамалары сүзлеге» барлыкка килде.

Сезгә сүзлегебезнең кыскартылган төрен тәкъдим итәбез. Алга таба сүзлегебез тагын да тулыланыр, ул халык һөнәрчелегенең башка төрләрен дә үз эченә алыр дип уйлыйбыз. Бу сүзлек татар халык һөнәрчелеге белән кызыксынучыларга, сынлы сәнгать дәресләрен алып баручы укытучыларга, сәнгать мәктәбенең рәсем бүлегендә укучыларга аеруча файдалы булыр дип ышанып калабыз.

**Каюлы күн һөнәрчелегендә кулланыла торган атамалар**

Идел буе болгарлары югары сыйфатлы тире эшкәртү осталыгы белән дан тоткан. Казан осталары җитештергән бизәкле аяк киемнәренә чит илләрдә дә ихтыяҗ зур булган. Күн эшкәртү ысулы татар милли сәнгатенең символына әверелгән. Бу һөнәр бүгенге көннәргә кадәр сакланган һәм каюлы күн стилендә тирене нәфис эшкәртү ысулы төрле әйберләр әзерләгәндә киң кулланыла.

***Азия аяк киеме (Азиатская обувь)*** — XVIII-XX гасырларда Россия мөселман халыкларында киң таралган, Казан артында җитештерелгән аяк

киемнәре төрләренең гомуми исеме: йомшак һәм каты табанлы читекләр, күн кәвешләр, башмаклар, чүәкләр.

***Булгар (Булгари)*** — Идел буе болгарлары тарафыннан җитештерелгән югары сыйфатлы кызыл һәм көрән төстәге күн сорты. XIII-XIX гасырда төрле илләргә чыгарылган йомшак өй итекләрен дә шулай дип атый башлыйлар. Фарсы телендә «булгар» — хуш исле төсле күн дигән мәгънәне аңлата.

***«Дворян» читекләре («Дворянские» полу- сапожки)*** — XIX гасыр ахыры-XX гасыр башын- да Казанның читек тегү кәсебендә хатын-кызлар өчен озын кунычлы заманча матур итеп эшләнгән читекләр барлыкка килә. Читекнең алгы ягында жепле бәйләү ясалган һәм кунычы казан җөе ысулында вак нәкыш белән бизәлгән була.

***«Казан» җөе («Казанский»/«татарский» шов)*** — кулдан киселгән күн кисәкләрен бер - берсенә теркәтеп тоташтыру ысулы. Мондый ысул ныклыгы һәм матурлыгы белән аерылып тора. Казан җөе без (шило) һәм чигү энәләре ярдәмендә өчкырлы казык (колодка) өстендә тегелә.





***Кәвеш (Кауши/кавуши)*** — өйдән чыкканда йомшак читек өстеннән киелә торган күн галошлар. XIX гасыр ахырында резина галошлар барлыкка килү сәбәпле, читек тегү кәсебеннән күн галошлар кысырыклап чыгарыла.

***Каюлы күн (Кожаная мозаика)*** — казан җөе ысулын кулланып башкарылган каюлы читек тегү кәсебе һәм каюлы күн сәнгате исеме.





***Озын кунычлы ир-атлар читеге (Вытяжные ичиги)*** — кара, куе-яшел, көрән, зәңгәр, чия төсендәге йомшак табанлы, бер арткы җөй белән тегелгән аяк киеме. Ул, башка читекләрдән аермалы буларак, тоташ киселгән тиредән тегелә. Читекнең кунычы аерым төстәге бизәкле кисем белән тәмамлана.

***Сәхтиян күн (Сафьян)*** фарсы телендә «эшкәртелгән кәҗә тиресе» дигән мәгънәне аңлата. Ачык төсләргә буялган югары сыйфатлы юка һәм йомшак тире. Иң киң таралган сәхтиян күн кызыл төстә булган.

***Читек (ичиги)*** – азиялеләрнең аяк киеме төре. Озын һәм кыска кунычлы йомшак табанлы өйдә киелә торган читек. Соңрак «читек» сүзе хатын-кызларның каты табанлы һәм биек үкчәле итекләренә карата да кулланыла башлый.





**Татар орнаментында чәчәк атамалары**

Казан татарларының декоратив-гамәли сәнгатендә чәчәкле үсемлек орнаменты мөһим урын алып тора. Чәчәкле үсемлекләр халкыбыз сәнгатенең һәр төрендә дә киң таралган, ә чәчәк мотивларының күптөрлелеге кайчак гаҗәпкә калдыра. Бизәкләрдә борынгы көнчыгыш дала үсемлеге (лалә, лотос, пальметта) белән беррәттән, соңрак килеп чыккан бакча һәм кыр чәчәкләре дә урнаштырыла. Бу күптөрле чәчәк дөнясында, табигать мотивлары белән бергә, фантастик чәчәкләр дә зур урын били.

***Алтын чәчәк*** *(хризантема)* — чәчәкләре төрле төстә, таҗ яфракчыклары кәрзин формасында оешкан декоратив үсемлек.
***Акчәчәк*** *(ромашка)* — сары урталы, ак таҗ яфракчыклы чәчәкле үсемлек.
***Дәлия чәчәге*** *(георгин)* — кызыл, сары, алсу, шәмәхә, ак эре чәчәкле декоратив үсемлек.
***Канәфер чәчәге*** *(гвоздика)* — кызыл, алсу, шәмәхә, ак төстәге чәчәкле үсемлек.
***Кашкарый*** *(астра)* — төрле төстә чәчәк ата торган, таҗ яфракчыклары кәрзин формасында оешкан чәчәкле үсемлек.
***Кыңгырау чәчәк*** *(колокольчик)* — шәмәхә яки куе зәңгәр төстәге, чәчәге кыңгырауга охшаган үсемлек.
***Лалә чәчәге*** *(тюльпан)* — чәчәкләре төрле төстә, өч эчке һәм өч тышкы таҗ яфракчыкларыннан тора. Лалә татар орнаментында иң еш очрый торган чәчәкләрнең берсе.
***Мәк чәчәге, җимешләре*** *(цветы и плоды мака)* — кызыл, алсу чәчәкле декоратив үлән үсемлек, җимешләре тартмалык формасында өлгерә.
***Чалмабаш*** *(пион)* — кызыл, алсу яки акэре чәчәкле декоратив үсемлек.

***Өч яфрак*** *(трилистник) — өч таҗдан торган катлауды яфраклы үсемлек.*

## Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар


1. Ф.Х.Валеев. Татарский народный орнамент. 2002.
2. М. Зайнуллин. "Казанская узорная кожа" . "Татарский мир", №23-24
3. http://tatmuseum.ru/my-product/shoes-for-women2/
4. http://izo-museum.ru/kollektsii/prikladnoe-iskusstvo/tatarskoe-dekorativno-prikladnoe-iskusstvo-respubliki-tatarstan